ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 33 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Фәррахов Айрат Зәки улы белән берлектә «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 33 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын кертергә.

2. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

3. Күрсәтелгән закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкил итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Фәррахов Айрат Зәки улын билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 194-VII ДС